**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы,
23нчейортЛаешш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2022елның 03 ноябре** **2685 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында**

Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә, «Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:

- мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмасына чираттан тыш кабул ителү хокукын бирү;
- белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында баланы карау һәм тәрбия өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) түләнә торган түләүдән азат итү;
- муниципаль мәгариф оешмаларында 1-11 сыйныф укучыларына бушлай ике тапкыр кайнар ризык (иртәнге аш, төшке аш) бирү;
- спорт учреждениеләренә, мәдәни-күңел ачу учреждениеләренә бушлай йөрү;
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт сәясәтен раслау турында» 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган«2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019-2025 елларга балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында каралган акчалар исәбенә түләүсез нигездә балаларны һәм яшьләрне савыктыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2022 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2021 елның 07 декабрендәге 3872 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карары (1 нче кушымта)

**нигезендә**, 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүчеләргә, ялны оештыруга юлламалар белән тәэмин иткәндә, беренче чират хокукы бирелә.

2. Әлеге карарда каралган ярдәм чараларын бирү Россия Федерациясе гражданнары Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт үткән чорда гамәлгә ашырыла.

3. Ярдәм чаралары муниципаль учреждение җитәкчесе исеменә язма гариза, хәрби комиссариат белешмәсе (повестка күчермәсе), бала туу турында таныклык нигезендә бирелә.

4. Әлеге карарда каралган өстәмә социаль ярдәм чаралары өчен мөрәҗәгать Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә хәрби хезмәткә чакырылган гражданның хәрби хезмәткә алынган көненнән дә иртәрәк гамәлгә ашырылмый.

5. Ата-аналар (законлы вәкилләр) ярдәм чараларын күрсәтү өчен нигезләрне югалткан очракта, ата-аналар (законлы вәкилләр) ярдәм күрсәтү өчен нигезләр югалганнан соң 10 календарь көн эчендә бу турыда муниципаль учреждение җитәкчесенә раслаучы документлар белән хәбәр итәргә тиеш.

6. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарның пунктында күрсәтелгән ярдәм чараларын үз вакытында күрсәтүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карар нигезендә ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү тиешле елга һәм план чорына Лаеш муниципаль районы бюджетыннан бюджет ассигнованиеләре исәбенә гамәлгә ашырыла.

8. Бу карар 2022 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

9. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.А. Новиков

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районының
2022 елның «03» ноябрендәге
2685 номерлы Башкарма комитет
карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының көндезге лагерьларында Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләре балаларының ялларын оештыру

| Лагерь оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Кеше саны | Көннәр саны | Юлламаның бәясе, сум. | Ата-ана взносы сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| Мәктәп алды лагерьлары | Лаеш муниципаль районы | 15 | 7 | 1311,10 | 2950,50 |

## Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан балалар сәламәтләндерү лагерьларында мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләре балаларының ялларын оештыру

| Лагерь оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Кеше саны | Көннәр саны | 1 балага максатчан кертем бәясе, сум. | Максатчан кертем, сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| Лаеш муниципаль районының «Звездный» БСЛ | Татарстан Республикасы | 3 | 7 | 9500,00 | 28500,00 |